# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Сәрдә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

08.09.2022 ел

№ 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2022 елның 08 сентябрендә узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенә керүче Сәрдә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең Сәрдә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- ТР Саба муниципаль районы Сәрдә торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (балчыгын тигезләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл читләрен тигезләү, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 168 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 88 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 88 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеген составына керүче Сәрдә торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2.«2023 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенә керүче Сәрдә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең Сәрдә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?- дигән сорау буенча:

1) ТР Саба муниципаль районы Сәрдә торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (балчыгын тигезләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл читләрен тигезләү, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип таныpга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shikshi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шекше авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Хәйртдинов